**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 декабрендәге 4413 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 5 сентябрендәге 5320 номерлы карары белән расланган «Молодежный» территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 5 сентябрендәге 5320 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 23 августындагы 2812 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 954 номерлы, 2024 елның 25 мартындагы 1072 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 5360 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Молодежный» территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат органнарының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 декабрендәге
4413 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 5 сентябрендәге 5320 номерлы карары белән расланган «Молодежный» территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

Әлеге үзгәрешләр аерым характеристикаларны һәм чиратны төгәлләштерү максатыннан кертелә.

1. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә, 3 пунктның 2 таблицасында:

1.1. 2 юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Билгелә неше** | **Исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Сыйдырышлылыгы** | **Җир кишәрлеге мәйданы, га** |
|---|---|---|---|---|
| «Ш | Гомуми белем бирү мәктәбе | Урыннар | 1224 | 2,89» |

1.2. 21, 22 юлларны түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Билгелә неше** | **Исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Сыйдырышлылыгы** | **Җир кишәрлеге мәйданы, га** |
|---|---|---|---|---|
| «КП-1 | Күпкатлы паркинг булган күпфункцияле объект | Машина урыны | 496 | 0,3037 |
| КП-2 | Күпкатлы паркинг | Машина урыны | Кимендә 441 | 0,5199» |

2. Кызыл линияләр, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, федераль, җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымында экспликацияне төшереп калдырырга.

3. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмәдә:

3.1. «Проектны гамәлгә ашыруның I чираты» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бирергә:

«Проектны гамәлгә ашыруның I чираты:

- күпфатирлы йортлар (1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 һәм 8 корпуслар) төзелешенә рөхсәт алу;

- күпкатлы паркинг булган 496 урынлык күпфункцияле объект төзелешенә рөхсәт алу;

- кимендә 441 урын булган күпкатлы паркинг төзелешенә рөхсәт алу;

- су белән тәэмин итү, су чыгару, электр белән тәэмин итү, котельный, җирле чистарту корылмалары (I, II, III) өчен инженерлык челтәрләрен төзү;

- җирле әһәмияттәге урам төзелеше (Ул.);

- күпфатирлы йортларны (1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8 корпуслар) файдалануга тапшыру, күпкатлы паркинг (КП-1) булган, 496 урынга исәпләнгән күпфункцияле объектны файдалануга тапшырганчы, парковка урыннары яссылыктагы 830 урынлык вакытлыча парковкада оештырыла (гомуми белем бирү мәктәбе һәм балалар бакчасы урнаштыру өчен билгеләнгән 16:16:120601:17627 һәм 16:16:120601:21907 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә);

- I чиратны тәэмин итү өчен күпкатлы паркинг (КП-1) булган 496 урынга исәпләнгән күпфункцияле объектны файдалануга тапшыру;

- I чиратны тәэмин итү өчен кертеп төзелгән торак булмаган биналар белән кимендә 441 урынлы күпкатлы паркингны (КП-2) файдалануга тапшыру»;

3.2. «Проектны гамәлгә ашыруның II чираты» бүлегендә дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«- күпфатирлы йортларны (9 һәм 10 корпуслар) һәм кимендә 441 машина урыны булган паркингны (КП-2) файдалануга кертү кирәкле машина урыннары санын тәэмин итә»;

3.3. нигезләмәгә «Территорияне планлаштыру проектын гамәлгә ашыру этаплары һәм максималь сроклары» дигән таблица (искәрмәләр белән) өстәргә:

«Территорияне планлаштыру проектын гамәлгә ашыру этаплары һәм максималь сроклары

| **Капиталь төзелеш объектлары төрләре** | **Объектлар** | **Максималь сроклар, еллар** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (җир кишәрлеген формалаштыру/архитектура ягыннан проектлаштыру /экспертиза)** | **Төзелеш*** | **Төзелеш территориясендә урнашкан булган объектларны сүтү** |
| 1 нче чират | | | | |
| Торак билгеләнеше | Гомуми мәйданы 3,3 мең кв.м булган кертеп төзелгән торак булмаган биналар белән фатирларның гомуми мәйданы 55,6 мең кв.м булган күпфатирлы торак йортлар (1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8 корпуслар) | 2025 | 2026 | Территориядә сүтелергә тиешле объектлар юк |
| Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге | КП-1 – 496 урынга исәпләнгән күпкатлы паркинг белән күпфункцияле объект | | 2026 елның I кварталы | |
| Инженерлык инфраструктурасы | Инженерлык инфраструктурасы объектлары | | 2026 | |
| Транспорт инфраструктурасы | Әнәс Таҗетдинов урамы | | - | |
| 2 нче чират | | | | |
| Торак билгеләнеше | Гомуми мәйданы 1 мең кв.м булган кертеп төзелгән торак булмаган | 2025 | 2026 | |

| **Капиталь төзелеш объектлары төрләре** | **Объектлар** | **Максималь сроклар, еллар** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (җир кишәрлеген формалаштыру/архитектура ягыннан проектлаштыру /экспертиза)** | **Төзелеш*** | **Төзелеш территориясендә урнашкан булган объектларны сүтү** |
| | биналар белән фатирларның гомуми мәйданы 16,6 мең кв.м булган күпфатирлы торак йортлар (9, 10 корпуслар) | | | Территориядә сүтелергә тиешле объектлар юк |
| Социаль инфраструктура | 260 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү объекты | | 2030* | |
| | 1224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбе | | | |
| Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге | КП-2 – кимендә 441 урын булган күпкатлы паркинг | | 2026 елның IV кварталы | |

*Вакыт дәүләт һәм муниципаль программалар формалаштыруны исәпкә алып төгәлләштерелергә мөмкин.

Искәрмәләр:

- төзелеш эшләрен параллель алып барырга мөмкин. Социаль объектларны дәүләт финанслау программасына кертүгә карап, төзелеш этабына төзәтмәләр кертелергә мөмкин;
- төзелеш алып барылмаган территорияләрдә вакытлыча парковкалар урнаштыру рөхсәт ителә».